Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Кырынды авыл җирлегенең Кырынды торак пунктында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның 19 октябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлегенең Кырынды авылында гражданнар җыены **карар бирде**:

1. Кырынды авыл җирлеге Кырынды авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, иректән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Кырынды авылы Совет урамы буенча юлны ремонтлау һәм вак таш җәю.
- Кырынды авыл кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы аварияле һәм коры яшел үсентеләрне кистерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе И. И. ЗАКИРОВ